**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**Алькеевского**
**муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әлки**
**муниципаль районы**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Адрес: 422870, РТ, с. Базарные Матаки, ул. Крайнова, 56
тел: 8 (84346) 2-17-60

Адресы: 422870, РТ, Базарлы Матак авылы, Крайнов ур., 56
факс: 8 (84346) 2-17-60


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2020 елның 12 мае** **191№**

Аренда түләүләрен түләүне азат итү
өлешендә кече һәм урта эшкуарлык
субъектларына ярдәм итү чаралары турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 19 мартындагы «Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм чаралары турында» 670-р номерлы күрсәтмәсенә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 3 апрелендәге «Яңа коронавирус йогышы таралу нәтиҗәсендә хәл начараю шартларында, аеруча зыян күргән Россия икътисады тармаклары исемлеген раслау турында»гы 434 номерлы карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 22 апрелендәге 821-р номерлы күрсәтмәсенә таянып, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты Карар итте:

1. Татарстан Республикасы «Әлки муниципаль районының милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУнә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының муниципаль казнасын һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен (алга таба - муниципаль милек)тәшкил итүче муниципаль мөлкәтне (шул исәптән җир кишәрлекләрен дә) арендалау шартнамәләре буенча тәэмин итәргә:

а) арендаторлар мөрәҗәгать иткән көннән алып 7 эш көне дәвамында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының бердәм реестрына кертелгән, яңа коронавирус йогышы таралу нәтиҗәсендә килеп туган хәл начараю шартларында Россия икътисадының тармакларында эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы, исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 3 апрелендәге «Яңа коронавирус йогышы таралу нәтиҗәсендә хәл начараю шартларында, аеруча зыян күргән Россия икътисады тармаклары исемлеген раслау турында»гы 434 номерлы карары белән расланган аеруча күп зыян күрүчеләр белән 2020 елның апрель-июнь айларында муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча мондый арендаторларны аренда түләүләреннән азат итүне күздә тоткан өстәмә килешүләр төзүне. Күрсәтелгән аренда түләүләрен түләүдән азат итү аренда килешүендә күрсәтелгән төр (эшчәнлек төрләрен) гамәлгә ашыру өчен аннан файдалану максатларында муниципаль мөлкәтне арендага бирү каралган булса һәм күрсәтелгән эшчәнлек төрен (эшчәнлек төрләрен) гамәлгә ашыру өчен тиешле

мөлкәттән файдалануны раслый торган документлар булган очракларда гамәлгә ашырыла;

б) Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми сайтында арендаторлар – кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен әлеге пунктның «а» пунктчасы нигезендә өстәмә килешүләр төзү мөмкинлеге турында мәгълүмат урнаштыруны.

2. Әлеге карар нигезендә күрсәтелгән аренда түләүләрен түләүдән азат итү Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимы кертелгән датага аларның муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча узган чорда аренда түләүләрен түләү буенча йөкләнгән бурычы булмаган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының бердәм реестрына кертелгән әлеге карарның 1 пунктындагы «а» пунктчасында каралган эшчәнлек төрен (төрләрен) гамәлгә ашыручы рендаторларга - кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына карата гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы «Әлки муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы» МКУнә Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына әлеге карарның үтәлеше турында, 2020 елның II кварталыннан башлап, кварталдан соң килүче айның 10 числосыннан да соңга калмыйча, мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми https://alkeevskiy.tatarstan.ru сайтында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы http://pravo.tatarstan.ru хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасының «Әлки муниципаль районы Җир һәм милек мөнәсәбәтләре палатасы» МКУнә йөкләргә.

**Җитәкче:** **И.В.Юсупов**